ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.06.2023 Олы Кайбыч ав. №257

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 31 гыйнварындагы 21 номерлы карары белән расланган бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы «Бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану, күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 31 гыйнварындагы 21 номерлы карары белән расланган бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип тану һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.4.1. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Муниципаль хезмәт:

әлеге административ регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, гаризаны теркәгән көннән алып 30 календарь көн дәвамында;

гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә зыян күргән торак бинаның хуҗасы, хокук иясе яки яллаучысының гаризасы теркәлгәннән соң 20 календарь көн эчендә;

бинаны карау акты төзелгән очракта бер ай эчендә күрсәтелә (4нче кушымта).».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А. Н. Макаров